Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 22 апрелендә теркәлде, № 2700

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

Боерык

27.02.2015 Казан ш. №1156/15

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле белем алу нигезендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль мәгариф оешмаларына укучыларны кабул иткәндә яки күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” 29 декабрь, 2012 ел, № 273-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законының 67 статьясындагы 5 пунктын һәм “Мәгариф турында” 22 июль, 2013 ел, №68-ТРЗ Татарстан Республикасы законының 4 статьясын үтәү, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче укучыларның индивидуаль ихтыяҗларыннан, теләкләре һәм сәләтләреннән чыгып, дәүләти һәм муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан төп гомуми һәм урта белем бирүне тәэмин итү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1.Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле белем алу нигезендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль мәгариф оешмаларына укучыларны кабул иткәндә яки күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибен расларга.

2.Муниципаль мәгариф идарәсе органнары җитәкчеләренә бу боерыкны мәгариф оешмалары җитәкчеләре, укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) игътибарына җиткерүне тәкъдим итәргә.

3.Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.Р.Мөхәммәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары –

министр Э.Н.Фәттахов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 27.02.2015 ел, №1156/15 боерыгына кушымта

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле белем алу нигезендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль мәгариф оешмаларына укучыларны кабул иткәндә яки күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру тәртибе

1.Бу Тәртип аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле белем алу нигезендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль мәгариф оешмаларына укучыларны кабул иткәндә яки күчергәндә индивидуаль сайлап алуны (алга таба – индивидуаль сайлап алу) оештыруны җайга сала.

2.Укучыларны индивидуаль сайлап алу түбәндәге очракларда билгеләнә:

–аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле белем алу нигезендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы

дәүләти һәм муниципаль мәгариф оешмаларына укучыларны кабул иткәндә (күчергәндә);

–укучыларны профильле белем бирүне тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларына кабул иткәндә (күчергәндә), “кадетлар мәктәбе”, “кадетлар корпусы” махсус атамалар белән гомуми белем бирү оешмаларына кабул итүне (күчерү) кертеп.

3.Белем бирү оешмаларында аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү һәм (яки) профильле белем бирү нигезендәге сыйныфлар ачу турында карар мәгариф оешмасы тарафыннан, белем бирү өлкәсендә идарәне хәл итүче җирле үзидарә органы һәм гамәлгә куючысы белән үзара килештереп, кабул ителә.

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү һәм (яки) профильле белем бирү сыйныфлары укучыларның, ата-аналарның (законлы вәкилләр) мәнфәгатьләреннән чыгып ачыла.

4.Гаризаларны тапшыру сроклары, вакыты, урыны һәм индивидуаль сайлап алу процедурасы турында укучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләр) хәбәр итү мәгариф оешмасы тарафыннан рәсми сайт аша, укучылар һәм ата-аналар җыелышларында, мәгълүмати стендлар, массакүләм мәгълүмат чаралары аша индивидуаль сайлап алу башланырга ким дигәндә 30 көн кала хәл ителә.

5.Укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру мәгариф оешмасы тарафыннан бу Тәртип һәм мәгариф эшчәнлеген оештыру һәм тормышка ашыруның төп мәсьәләләре буенча, шул исәптән укучыларны кабул итү кагыйдәләрен, укучыларны күчерү, уку йортыннан чыгару һәм торгызу

тәртибен һәм нигезләрен, мәгариф оешмасы белән укучылар һәм (яки) балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләр) арасындагы мөнәсәбәтләрне туктатып тору һәм туктату тәртибен җайга салучы локаль норматив актлар нигезендә хәл ителә.

6.Төп гомуми белем алу өчен укучыларны аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру, укучының индивидуаль белем казанышлары портфолиосыннан чыгып, тирәнтен өйрәнелә торган фән (фәннәр) буенча башлангыч аттестация нәтиҗәләренә туры китереп хәл ителә.

7.Урта гомуми белем алу өчен укучыларны аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү яки профильле укыту сыйныфларына кабул иткәндә яисә күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру, тирәнтен өйрәтү яки профильле укыту фәннәре буенча дәүләт йомгаклау аттестациясеннән чыгып, өлгереш нәтиҗәләре нигезендә хәл ителә.

Укучыларны индивидуаль сайлап алу критерийләре, гамәлгә куючысы белән килештереп, мәгариф оешмасының локаль норматив актлары нигезендә билгеләнә.

9.Төп гомуми һәм урта гомуми белем мәгариф программаларын тормышка ашырып, физик культура һәм спорт өлкәсендә һөнәр алды өстәмә белем бирү программалары белән интеграцияләнгән яки төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары белән интеграцияләнгән сәнгать өлкәсендә урта һөнәри белем мәгариф программалары белән интеграцияләнгән мәгариф оешмаларында урта белем алу өчен укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру сәнгать яки спортның аерым төре белән

шөгыльләнүгә сәләтне бәйләү нигезендә, шулай ук тиешле спорт төре белән шөгыльләнүгә каршы килүләр булмаганда хәл ителә.

10.Укучыларның түбәндәге категорияләре аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү нигезендәге мәгариф оешмасына (сыйныф) яки профильле укытуны тормышка ашыручы мәгариф оешмасына (сыйныф) кабул ителгәндә яки күчерелгәндә өстенлекле хокукка ия:

–Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының муниципаль, төбәк һәм йомгаклау этапларында җиңүчеләр һәм призерлар, шулай ук Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән тирәнтен өйрәтелә торган фәннәр яки профильле белем бирү фәннәре буенча олимпиадаларда җиңүчеләр һәм призерлар;

–мәгариф өлкәсендә идарәне хәл итүче Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган, тирәнтен өйрәтелә торган фән яки профильле белем бирү фәннәре буенча муниципаль, республика, бөтенроссия һәм халыкара конференцияләрдә һәм фәнни-тикшеренү хезмәтләре яки проектлары бәйгеләрендә җиңүчеләр һәм призерлар;

–тиешле аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфында яки тиешле профильле укыту сыйныфында төп гомуми яки урта гомуми белем программаларын үзләштергән, тирәнтен өйрәнелә торган уку фәннәре яки профильле укыту фәннәре буенча яхшы һәм бик яхшыга укып, башка мәгариф оешмасыннан күчерү тәртибендә мәгариф оешмасына кабул ителә торган укучылар;

–ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар;

–психолог-медицина-педагогик комиссия һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәләре нигезендә тиешле мәгариф оешмаларында белем алуга каршы килүләре булмаган һәм мәгариф оешмаларында сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен кирәкле шартлар тудырылган сәламәтлеге мөмкинлеге чикләнгән укучылар, инвалид балалар һәм инвалидлар.

11. Укучыларның түбәндәге категорияләре “кадетлар мәктәбе”, “кадетлар корпусы” дигән махсус атамалар белән гомуми белем бирү оешмаларына кабул итүдә өстенлекле хокукка ия;

–ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар;

–контракт нигезендә хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең балалары;

–федераль закон нигезендә хәрби хезмәт каралган федераль башкарма хакимияте органнарының дәүләти гражданлык хезмәткәрләре һәм гражданлык персоналы балалары;

–хәрби хезмәттә булуның чик яшенә җитү, сәламәтлеге буенча яки оештыру-штат чараларына бәйле рәвештә хәрби хезмәттән киткән һәм хәрби хезмәтенең гомуми озынлыгы егерме ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән гражданнарның балалары;

–хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган яки хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә имгәнү (яралану, җәрәхәтләнү, контузия алу) яисә авыру сәбәпле үлгән хәрби хезмәткәрләрнең балалары;

–Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары балалары;

–эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең балалары;

–эчке эшләр органнарында хезмәт итүнең чик яшенә җитүе, сәламәтлеге буенча яки оештыру-штат чарларына бәйле рәвештә эчке эшләр органнарында хезмәт итүдән киткән һәм хезмәт итүнең гомуми озынлыгы егерме ел һәм аннан күбрәк тәшкил иткән гражданнарның балалары;

–эчке эшләр органнарында хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә имгәнү яки сәламәтлеккә башка төрле зыян килү яисә авыру аркасында һәлак булган яки үлгән эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең әлеге затлар иждивениесендә булган балалары;

–прокуратура органнарында хезмәт итү чорында имгәнү яки сәламәтлеккә башка төрле зыян килү яки эштән киткәннән соң хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә сәламәтлеккә зыян килү аркасында һәлак булган яки үлгән прокурор хезмәткәрләренең балалары;

–Федераль законнар нигезендә билгеләнгән очракларда башка затлар.

12.Индивидуаль сайлап алуны оештыру өчен мәгариф оешмасының педагогик, җитәкче һәм башка хезмәткәрләреннән һәм укучыларны индивидуаль сайлап алуда катнашуга компетенцияле мәгариф оешмасы идарәсенең коллегиаль органнары вәкилләре (мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең гомуми җыелышы (конференция), педагогик советы һ.б.) арасыннан комиссия оештырыла.

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү яки профильле укыту сыйныфларына укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру өчен

комиссия составына тирәнтен өйрәнелә торган яки профильле укыту фәннәре буенча белем бирүче педагогик хезмәткәрләр мәҗбүри тәртиптә кертелә.

Комиссия әгъзалары саны, персональ составы, комиссияне булдыру һәм эшен оештыру тәртибе, гамәлгә куючысы белән килештереп, мәгариф оешмасының локаль норматив актлары нигезендә билгеләнә.

13.Индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре һәм комиссия карары нигезендә укучыны аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү сыйныфына яки профильле сыйныфка кабул итү турында мәгариф оешмасының локаль акты чыгарыла.

14.Мәгариф оешмасы комиссия карары турында укучының ата-анасына (законлы вәкил) тиешле фән яки профиль буенча комиссия тарафыннан беркетмә имзаланганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.

15.Укучының ата-анасы (законлы вәкилләр) комиссия карары белән килешмәгән очракта, һәр фән яки профиль буенча нәтиҗәләр белән танышканнан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, укучы индивидуаль сайлап алу үткән мәгариф оешмасында булдырылган низагларны хәл итү комиссиясенә, әлеге мәгариф оешмасының локаль норматив актында билгеләнгән тәртиптә, язмача гариза тапшыру юлы белән апелляция җибәрүгә хокуклы.

16.Укучыларны индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре буенча аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү сыйныфына (сыйныфлар) яки профильле белем бирү сыйныфына (сыйныфлар) кабул итүдән баш тарту укучыны мәгариф оешмасыннан чыгаруга нигез булып тора алмый.

Дәүләт яки муниципаль мәгариф оешмасына фәкать буш урыннар булмау сәбәпле генә кабул итүдән баш тартылырга мөмкин. Мәгариф оешмасында урын бирүдән баш тарту очрагында, укучының ата-анасы (законлы вәкилләр), баланы башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру турында мәсьәләне хәл итү өчен, мәгариф өлкәсендә идарәне хәл итүче җирле үзидарә органнарына турыдан-туры мөрәҗәгать итә.

Мәгариф өлкәсендә идарәне торышка ашыручы җирле үзидарә органы индивидуаль сайлап алу аша үтмәгән һәм индивидуаль сайлап алуда катнашмаган укучыларны гомуми белем бирү сыйныфларына (мәктәпләр) кабул итүгә шартлар тудыра.

17.Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү сыйныфларында яки профильле белем бирү сыйныфларында укучылар фәннәр тирәнтен өйрәтелми торган сыйныфларга (булганда) яки профильле булмаган сыйныфларга (булганда) күчүгә хокуклы. Күчү укучының ата-анасы (законлы вәкилләр) гаризасы һәм мәгариф оешмасының вәкаләтле коллегиаль органы карары нигезендә хәл ителә.

18.Индивидуаль сайлап алуны оештыру мәгариф оешмасы җитәкчесе исеменә укучының ата-анасы (законлы вәкилләре) язган шәхсән гаризасы буенча, ата-ананың (законлы вәкил) шәхесен раслаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп, яки “Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында” 25 июль, 2002 ел, №115-ФЗ Федераль законның 10 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә чит ил гражданинның шәхесен раслаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп хәл ителә.

Гариза мәгариф оешмасы тарафыннан билгеләнгән индивидуаль сайлап алуны үткәрү срогына кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Мәгариф оешмасы әлеге гаризаны, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-коммуникация челтәрләреннән файдаланып, электрон документ рәвешендә кабул итә ала.

19.Укучының ата-анасы (законлы вәкилләр) гаризасында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а)укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда);

б)укучының туу датасы һәм урыны;

в)укучының ата-анасының (законлы вәкилләр) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда);

г)укучыларны индивидуаль сайлап алу оештырылган, аларны кабул итү яки күчерү өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтү сыйныфы яки профильле белем бирү сыйныфы;

д)бу Тәртипнең 10, 11 пунктларында күрсәтелгән укучының тиешле сыйныфка кабул ителүгә өстенлек хокукларга ия булуын дәлилләгән нигезләр.

Бу Тәртипнең 10, 11 пунктларында күрсәтелгән нигезләрне раслау өчен тиешле документлар тапшырыла.

20.Укучының ата-анасы (законлы вәкилләр) гаризага һәм шәхесне раслаучы документларга өстәмә рәвештә баланың туу турында таныклыгының төп нөсхәсен яки мөрәҗәгать итүченең туганлыгын (яки укучыга хокуклар бирүнең законлыгын) раслаган, билгеләнгән тәртиптә

расланган документ күчермәсен, шулай ук баланың туу турында таныклыгының төп нөсхәсен яки мөрәҗәгать итүченең туганлыгын (яки укучыга хокуклар бирүнең законлыгын) раслаган, документ күчермәсен күрсәтә.

21. Укучыны профильле укыту сыйныфларына кабул иткәндә яки урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укытуга башка мәгариф оешмасыннан күчергәндә индивидуаль сайлап алуны оештыру өчен укучының ата-анасы (законлы вәкилләр)  укучыга төп гомуми белем турында бирелгән дәүләт үрнәгендәге документны өстәмә рәвештә тапшыра.

22. Укучының чит ил гражданины яки гражданлыксыз зат булып торган ата-анасы (законлы вәкилләр) гаризага һәм шәхесне раслаучы документларга өстәп, мөрәҗәгать итүче белән туганлык мөнәсәбәтләрен (яки укучының хокуклары белән эш итүгә законлылыгын) раслаган документлар күчермәләрен (билгеләнгән тәртиптә расланган) һәм мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булуга хокукын раслаучы документын күрсәтә.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар барлык документларны рус телендә яки  билгеләнгән тәртиптә расланган рус телендә тәрҗемәсе белән тапшыра.

23. Физик культура һәм спорт өлкәсендә һөнәр алды өстәмә мәгариф программалары белән интеграцияләнгән төп гомуми һәм урта гомуми белем мәгариф программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында гомуми белем алу өчен укучыларны индивидуаль сайлап алуны оештыру максатында тиешле спорт төрле белән шөгыльләнүгә каршы килүләрнең булмавы турында медицина белешмәсе тапшырыла.

24. Балаларның ата-анасы (законлы вәкилләр), үзләренең теләгенә карап, башка документлар, шул исәптән баланың сәламәтлеге турында медицина белешмәсе тапшыруга хокуклы.

25. Укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләр) тапшырган документлар гаризаларын кабул итү журналында теркәүгә алына. Гариза теркәлгәннән соң ата-аналарга (законлы вәкилләр) документларны алу турында расписка (укучыны мәгариф оешмасына кабул итү турында гаризаның теркәү номеры һәм тапшырылган документлар исемлеге турында мәгълүматтан торган) тапшыра. Расписка документларны кабул итүгә җаваплы мәгариф оешмасының вазыйфаи заты имзасы һәм мәгариф оешмасының мөһере беләнраслана.

26. Документларны кабул иткәндә тапшырылган күчермәләр, укучының белем алу чоры дәвамында, мәгариф оешмасында саклана.

27. Мәгариф оешмалары укучыларны индивидуаль сайлап алганда гражданнарның белем алуга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хокукларны үтәүне, хәбәрдарлык һәм ачыклык шартларын булдыруны, укучыларның сәләтен һәм хирыслыгын бәяләүнең объективлыгын тәэмин итәргә тиеш.

28. Укучыларны аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү һәм (яки) профильле белем бирү сыйныфларына кабул итүдә яки күчерүдә бу Тәртиптә җайга салынмаган яктан индивидуаль сайлап алуны оештыру Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән үзара килештереп, комиссия тарафыннан билгеләнә.